# Укытучылар мәңге онытылмый, хөрмәт – сөю һәрчак саклана... ( ветеран укытучылар)



## Шәвәлиева Нәгыймә Сәлихҗан кызы

Шәвәлиева Нәгыймә апа 1928нче елда Мөслим районының Әмәкәй авылында Ямансаров Сәлихҗан һәм Кәримә гаиләсендә дөньяга килә.

1935 нче елда Ямансаровлар гаиләсе бәхет эзләп Ташкент якларына чыгып китә. Нәгыймә апа башлангыч белемне шул шәһәрдә ала. 1941 нче елда Бөек Ватан сугышы башлангач, алар гаиләләре белән туган авыллары Әмәкәйгә кайталар. Шул ук елны Нәгыймә апаның әтисе сугышка китә. Әтиләре Салихҗанны фронтка озатканда, алар мәйданнарны тотарлык куәтле кешенең сугыш кырында, дошман пулясы тиеп, мәңгегә ятып калыр дип күз алдына да китермиләр. Әмма Сталинград янындагы “җәһәннәм” утларыннан исән сау чыккан солдат 1943 нче елда Ленинград өчен барган яуда батырларча һәлак була. Бу вакытта Нәгыймә апа 5 нче класста укый.

1946 нчы елда мәктәпне тәмамлагач, Нәгыймә Сәлихҗан кызы Минзәлә педагогия училищесына укырга керә һәм аны 1950 нче елда тәмамлап, Әмәкәй җидееллык мәктәбенә рус теле укытырга кайта. Аны өлкән укытучылар сөенеп каршы алалар.

1953 нче елдан башлап (33 ел) Күбәк урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта.Читтән торып Алабуга педагогия институтын тәмамлый.

Тырыш хезмәте өчен Нәгыймә Сәлихҗан кызы “Хезмәт ветераны” медале һәм мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

Нәгыймә апаның укучылары арасында республикага танылган шәхесләр дә бар: Флүн Мусин, Харрас Әюпов, Наил Әюпов, Факил Сафин, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Мөдәмил Әхмәтов...

## Исхакова Сөгъдә Идрис кызы



Сөгъдә Идрис кызы 1929 нчы елның 10нчы апрелендә Татарстанның Мөслим районы, Мөслим авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Авыр сугыш елларына туры килгән заман фаҗигасе аркасында әтисез калган, йорт- җирсез үскән. Әнисе колхозда чәчүлек орлык агулаганда агуланып, гомерлек авыру булып кала. Шулай итеп, дүрт баланы һәм әнисен тәрбияләү иң өлкән бала Сөгъдәгә кала. Аның балалык һәм яшьлек еллары үзәкләргә үтәрлек авыр була, тормыш михнәтләрен күп күрергә туры килә. Шулай булса да, укуын ташламый. 1947 нче елда Мөслим урта мәктәбентәмамлый һәм шул ук мәктәптә пионервожатый булып эшли башлый.

1948 нче елда Казан укытучылар институтының физика-математика факультетына укырга керә һәм аны “5”легә генә тәмамлый.1950нче елда Мөслим районы Күбәк урта мәктәбендә укытучы булып эшли башлый.

1955 нче елда читтән торып Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. 27 яшьлек Сөгъдә апа Татарстан укытучылар съездына делегат итеп сайлана.

Ул безнең Күбәк урта мәктәбендә 42 ел математика укытучысы булып эшли, озак еллар уку-укыту эшләре буенча директор ярдәмчесе вазифасын башкара.

Сөгъдә апа балаларны чиксез яраткан, балалар да аның һәр сүзенә ышанганнар, хөрмәт иткәннәр. Ул балаларның мәктәп еллары күңеллерәк булсын өчен тырышкан.Исхакова Сөгъдә Идрис кызы - РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, “Иң югары категорияле укытучы” исемнәренә лаек була.

Ләкин тормыш рәхимсез. Олы абруйлы, тыйнак, көчле ихтыярлы, нечкә табигатьле Сөгъдә апа 1994 нче елда вафат була. Ләкин чын укытучы өчен аерылышулар юк. Ул үзенең укучылары белән һәрчак янәшә атлый.

1994 нче елның 25 нче октябрендә Күбәк урта мәктәбенең варислар дружинасына РСФСР ның халык мәгарифе отличнигы, Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы Сөгъдә Вәлиева-Исхакова исеме бирелә.



## Нуруллина Рәшидә Мирхәйдәр кызы


1944 нче елның 5 нче сентябрендә табигатьнең бик матур почмагына урнашкан Ташъелга авылында дөньяга килә. Куе урман һәм таулар эчендә утырган әлеге авылда балачак һәм яшьлек еллары үтә. Әтисе Мирхәйдәр абый – сугыш ветераны. Балачагы авыр сугыштан соңгы елларга туры килсә дә, тәртипле, эшчән һәм башкаларга ярдәмчел булып үсә Рәшидә Мирхәйдәровна.

1965 нче елда Минзәлә педучилещесын тәмамлап, яшь-яшь кыз бала Күбәк урта мәктәбенә эшкә кайта. Әнисе Мәрхәбә апаның: “Күбәк мәктәбенә генә эләкмәсәң ярар иде,” - дигән сүзләре дә куркытмый аны. Күбәк урта мәктәбендә бик күп еллар башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән Рәшидә Мирхәйдаровна Нуруллинаның озын һәм мактаулы хезмәт юлы шулай башлана.

Укытучыларның эше беркайчан да җиңел булмаган. Ә көчле Совет власте идеологиясе вакытында бигрәк тә. 600 бала укыган мәктәптә пионервожатый булып эшли башлаган яшь-яшь кызга да әлбәттә инде, җиңел булмаган. Күп төрле ярышлар, сборлар, линейкалар үткәрү өстенә, терлекчеләр янына барып, аларның эшенә йомгак ясарга да, концертлар әзерләргә дә, шул ук вакытта иртәнге 5 тә торып, радиоузелдан хуҗалык хәбәрләрен дә җиткерергә тиеш була ул. Агитатор да, пропагандист та, лектор да була бу өлгер кыз.

1970 нче елда тәүге беренчеләрен кабул итә ул. Башлангыч сыйныф укытучысы эшенең никадәр авыр һәм җаваплы икәнен бары тик үзе укыткан кеше генә белә. Хәреф тә таный белмәгән нәни йөрәккә белем бирү өчен никадәр сабырлык, көч кирәк. Үз эшен чын күңеленнән яратып башкара Рәшидә Мирхәйдәровна.

Уңган укытучыны мәктәп коллективы да, авыл халкы да бик тиз үз итә. Хезмәте барның – хөрмәте бар, ди халык. Рәшидә Мирхәйдәр кызының да хезмәте югары бәяләнә, ул “РСФСР мәктәпләренең мәгариф отличнигы” исеменә лаек була.



## Вәлиева Рәйфә Хатыйп кызы

1947 нче елның 25 августында Башкортстанның Бакалы районы Яңа Әлмәт авылында дөньяга килгән. Башлангыч белемне үз авылында алган, аннан соң шул ук районның Үмер авылы мәктәбендә, 9 нчы һәм 10 нчы сыйныфларны Мөслим районы Күбәк урта мәктәбендә укыган. Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, читтән торып Уфа шәһәрендә белем алган, Башкорт дәүләт университетының филология бүлегенбетереп, татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлегенә ия булган.

Рәйфәханым хезмәт юлын Бакалы районы Яңа Илек авылы мәктәбендә үз белгечлеге буенча башлап җибәрә. 1971 нче елның 14 нче августында тормыш юлын Күбәк авылы егете Мәгъсүм абый белән бәйли. 1972 нче елның 15 августында Рәйфә Хатыйповна Күбәк урта мәктәбенә укытырга килә. Үз эшен яратып,җиренә җиткереп иҗади якын килеп башкара. Акыллы, гадел кеше буларак, укучыларын бик ярата һәм һәр балага индивидуаль якын килә белә.Коллективта аралашучан, балалар белән уртак тел таба белүче, ата-аналар белән бердәм-тату эш оештыручы буларак танылa.

Күбәк урта мәктәбендә 36 ел буена татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Күп еллар мәктәп интернатында тәрбияче вазифасын намус белән үти. Хезмәт елларында җәмәгать эшләрен, агитатор, класс җитәкчесе кебек эшләрне олы бер осталык, дәрт белән башкара.

Рәйфә апа белән Мәгъсум абый ике бала үстерәләр. Кызы Гөлчәчәк Казан дәүләт университетының физика-математика бүлеген тәмамлый. Яр Чаллыда яши, Е.Н. Батенчук исемендәге Каматөзелеш көллиятендә укыту-методик бүлеген җитәкли. Улы Салават Алабуга дәүләт педагогия университетының тарих һәм юриспруденция бүлеген тәмамлаган. Яр Чаллыда яши, Технотрон-Метиз заводында актив сату буенча менеджер булып эшли.

Рәйфә Хатыйп кызы хәзерге вакытта вафат. Талантлы укытучы үз белемен башкаларга бирә, авырлыкларны җиңеләйтә, бала күңелен аңлый белә. Вәлиева Рәйфә Хатыйп кызы үзенең йомшак тавышы, сабырлыгы, үз эшенә күңелен биреп эшләве белән укучылары хәтерендә саклана.

## Вәлиева Әминә Вәҗи кызы



Уфа губернасы Минзәлә өязе Әмәкәй волостена кергән Бәкәбез авылында туган. Минзәлә педагогия училищесында, Алабуга укытучылар мәктәбендә, Казан дәүләт педагогия институтында укып, югары белем ала.

1941-1945 нче елларда - Октябрь җидееллык мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 1945-1948 нче елларда - Күбәк урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 1967-1974 нче елларда - шул ук мәктәптә хезмәткә өйрәтү буенча директор урынбасары. Агитатор, пропагандист, лектор, ата-аналар университеты ректоры, класс җитәкчесе кебек эшләрне зур осталык белән башкара.

Мәгариф бүлеге һәм Мәгариф министрлыгы тарафыннан 14 мәртәбә мактау грамотасы белән бүләкләнә, “Халык мәгарифе отличнигы”, ”СССР мәгарифе отличнигы”, ”Татарстанның атказанган укытучысы” дигән мактаулы исемнәр бирелә, “Хезмәттәге аерымлык өчен”, “1941—45 нче елларда Германияне җиңгән өчен” , ”Хезмәт ветераны” медальләренә лаек була.

Әминә Вәҗи кызы хәзерге вакытта вафат.

## Әмирова Ярия Әмирҗан кызы



1930 нчы елның 15 октябрендә Башкортстанның Илеш районы Ябалак авылында туа. Гаиләдә 7 бала тәрбияләнә. Шуларның алтысы – укытучы.

Ярия апа унынчы классны 1948 нче елда Актаныш урта мәктәбендә тәмамлый. Укытучы булып эшли башлый. 1951 нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтына читтән торып укырга керә. 1955 нче елда аны уңышлы тәмамлый, кулына татар теле һәм әдәбияты укытучысы дипломы ала.

1953 нче елда тормышка чыга. Әлеге вакытта ул Актаныш районы Аеш мәктәбендә эшли. Аннары Суыксу, Такталачык авылларында хезмәт юлын дәвам итә. 1960 нчы елда Иске Карамалы авылына күченеп киләләр. Шул елдан башлап, лаеклы ялга чыкканчы, Ярия Әмирҗан кызы Күбәк урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты, хезмәт дәресләрен укыта.

Ярия Әмирҗан кызы хәзерге вакытта вафат.



## Ибрагимов Ирхәт Гайсә улы

1930 нчы елның 7 июлендә Мөслим районы Иске Вәрәш авылында дөньяга килгән. 7 сыйныф тәмамлап Минзәлә педагогия училищесына укырга керә. Укуын дәвам итү максаты белән, Алабуга дәүләт педагогия институтына читтән торып, тарих факультетына укырга керә.

1952 нче елда Актаныш районы Иске Солтангол авылы мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Соңрак институты тәмамлаганнан соң тарих укытучысы итеп Актаныш районы Такталачык урта мәктәбенә күчерелә.

1953 нче елда Ярия апа белән тормыш корып җибәрәләр.

1960 нчы елда язмыш җилләре Ирхәт абыйның гаиләсен янә туган ягына кайтара. Күбәк урта мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли башлый. Күп еллар укыту эшләре буенча директор урынбасары вазыйфасын башкара.

Нык холыклы, тәртипне яратучы укытучыны 1969 нчы елда РОНО приказы белән Октябрь мәктәбенә директор итеп бигелиләр. Октябрь авылында яңа мәктәп төзү, нәкъ Ирхәт абый эшләгән чорга туры килә.

1985-1986 нчы уку елында Иске Үрәзмәт унъеллык мәктәпкә директор итеп билгеләнә һәм лаеклы ялга чыкканчы шул мәктәптә эшли.

Ирхәт Гайсә улы хәзерге вакытта вафат.



## Кәримов Мисалим Фахразый улы

1925 нче елда Мөслим районының Катмыш авылында туган. 1942нче елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлый. Бөек Ватан сугышына 1943 нче елда китә.

1946 нчы елның сентябреннән 1953 нче елга кадәр Катмыш мәктәбендә мөдир вазифасын башкара. 1953-1958нче елларда Иске Карамалы мәктәбендә мөдир булып эшли. 1958нче елдан 1985нче елга кадәр Яңа Карамалы башлангыч мәктәбендә мөдир вазифасын башкарып, лаеклы ялга китә.

Намуслы хезмәте өчен “Мәгариф отличнигы” исеменә лаек була.

Мисалим Фахразый улы хәзерге вакытта вафат.

## Гайров Рифкать Миңнехан улы



1926 нчы елның 6 июнендә Мөслим районы Күбәк авылында туган.

Күбәк башлангыч мәктәбен тәмамлаганнан соң, Әмәкәй урта мәктәбендә укуын дәвам итә.

1943 нче елны Совет армиясенә китә. Армиядән 1949 нчы елның азагында гына кайта. 1949 елда Күбәк урта мәктәбендә хәрби әзерлек һәм авыл хуҗалыгы механизациясе буенча укытучы булып эшли башлый. Шул ук вакытта Чистай авыл хужалыгы техникумында укый. Соңыннан Казан авыл хужалыгы институтында укып югары белем ала.

Рифкать Миңнехан улының егетләргә техника серләрен өйрәтү максаты белән, үзе булдырган остаханә, тирә-як мәктәпләрдә бердән-бер була. Күбәк урта мәктәбендә күп еллар намуслы хезмәт куеп, 1981 нче елда лаеклы ялга чыга.

## Борһанова (Кадыйрова) Зоха Габделхак кызы



1918 нче елның 8 мартында Оренбург губернасы Минзәлә өязе Бүләр волосте Табанлы-Күл авылында урта хәлле Габделхак һәм Шәрифә гаиләсендә туа.

Зоха апа бик зирәк була. Җиде яше дә тулмыйча, Табанлы-Күл башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1931 нче елда җиде классны тәмамлый. 13 яше тулгач, 1931 нче елдан алып, ике ел дәвамында культармеецлар составында укытучы булып эшли. 1933-1938 нче елларда Минзәлә педагогия техникумында укый һәм шул ук вакытта Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. 1938-1940 нче елларда Тойгелде җидееллык мәктәбендә башлангыч классларны укыта, 1940-1942 нче елларда Зоха апа тулы булмаган Салауз-Мухан урта мәктәбендә, Керәш Шуран химия-биология укытучысы булып эшли. 1942 нче елның 25 нче

августында тулы булмаган Симәк урта мәктәбедә татар теле укытучысы итеп күчерелә. Ул анда математика, химия, биология фәннәрен һәм башлангыч классларны укыта.

1946 нчы елның 12 сентябрендә Кадыйрова Зоха фин һәм Бөек Ватан сугышын үткән Борһанов Мирза белән никахлашып, гаилә корып, бергәләп яши башлыйлар.

1951 нче елның август аенда Мирза абый Иске Карамалы авылының башлангыч мәктәбендә мөдир, партком секретаре булып, ә Зоха апа Күбәк мәктәбендә химия-биология укытучысы булып билгеләнә.

1968 нче елда, 32 ел укытканнан сон, Зоха апа лаеклы ялга чыга.

## Әхмәтҗанов Васил Миркасим улы



1933 нче елда Түреш авылында туа. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Анда музыка грамотасына өйрәнә. Шигырьләр иҗат итә. Драмтүгәрәк җитәкчесе. Үзешчән композиторлар союзына кабул ителә. Мәскәү университетының музыка факультетын читтән торып тәмамлый. Бик күп җырлар иҗат итә. Күбәк урта мәктәбендә, Иске Карамалы мәдәният йортында эшли. Озак еллар пропагандист, комсомол оешмасе секретаре вазифаларын башкара, колхозның гомуми стена газетасының редакторы, фәнни һәм политик белемнәр тарату җәмгыятенең Иске Карамалы авыл группасының бюро рәисе. Халык мәгарифе отличнигы.

1976 нчы елның 7 нче гыйнваренда вафат була.

# Мирхайдарова Фәрия Әхмәтхан кызы



1940 нчы елның 24 нче мартында, Әгъбәз авылында Вәлиевлар гаиләсендә дөньяга киләә.1957 нче елда Байсар урта мәктәбен тәмамлап, Минзәлә педагогия көллиятенә укырга керә.1960 нчы елда хезмәт юлын Актаныш районы Аеш авылында башлангыч сыйныф укытучысы буларак башлап җибәрә.

1968 нче елда Күбәк урта мәктәбендәрус теле һәм әдәбиятын укыта башлый. 1971 нче елда читтән торып Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлый.

1980 нче елның 4 нче июлендә Россия мәгариф министрлыгының мактау грамотосы беләнн бүләкләнә.

1988 нче елның 23 нче июлендә озак еллар намуслы хезмәт куйганы өчен «Хезмәт ветераны» медаленә лаек була.

1995 нче елда Мирхайдарова Фәрия Әхматхан кызы лаеклы ялга чыга.

1999 нчы елның 2 нче сентябрендә Татарстан президенты Указы нигезендә Хезмәт ветераны исеме бирелә.



## Маликова Зөлфия Якуп кызы

Мөслим районы Салауз-Мухан авылында 1946 нчы елның 8 октябрендә колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 1954 нче елда Салауз-Мухан җидееллык мәктәбенә 1 нче класска укырга керә. Аны тәмамлагач, 1961 нче елда Мөслим урта мәктәбенең 8 нче классына укырга бара. 1965 нче елда 11 нче классны тәмамлап, Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. 1970 нче елда институтны тәмамлап, Күбәк урта мәктәбенә эшкә килә, рус теле һәм әдәбияты дәресләре укыта башлый. 2002 нче елдан, лаеклы ялга чыкканчы, рус теле һәм әдәбияты белән беррәттән татар теле һәм әдәбияты дәресләрен дә укыта.

1971 нче елда Күбәк авылы егетенә тормышка чыга. Иншат абый белән өч бала тәрбияләп үстерәләр. Олы уллары Илдар – участок инспекторы, кызлары Илсөяр Әлмәт шәһәрендә тәрбияче булып эшли. Кече уллары Илнур, әнисенең юлын дәвам итеп, Күбәк урта мәктәбендә география һәм технология дәресләре укыта. Зөлфия апа хәзерге көндә кече улы тәрбиясендә яши, аларга оныклар үстерергә булыша.




# Юнысова Сәрия Мизхәт кызы

Туган җире - Мөслим районы Иске Вәрәш авылы.Башлангыч мәктәп белемен үз авылында ала, урта класс белемен Мөслим мәктәбендә дәвам итә.

Керү имтиханнарын яхшы билгеләргә тапшырып, Алабуга дәүләт педагогия институтынына математика-физика бүлегенә укырга керә. Уку йортын уңышлы тәмамлаганнан соң, 1976 нчы елда Сәрия Мизхәт кызы Кубәк урта мәктәбенә физика укытучысы итеп эшкә билгеләнә. Үз эшен яратып эшләүче яшь белгечне, бер ел эшләгәч тә, директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп билгелиләр. Ул вакыттагы мәктәп директоры Зәйнак Вәзи улы, көчле педагог, яхшы теоретик, күп укучы, документацияне төгәл белүче, дәресләрне тыңлаучы, тәрбия чараларын берсендә калдырмыйча бәяләүче директор була. “Аның кул астында эшләү зур мәктәп булды”, - дип уртаклаша Сәрия Мизхәт кызы.

Сәрия Мизхәтовнаның укучылары ел саен район олимпиадаларында призлы урыннар ала, республика олимпиадаларында катнаша. Бүгенге көндә дистәдән артык укучысы республика мәктәпләрендә физика фәнен укыта.

8 ел тәрбия эшләре буенча, 13 ел укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли.

Сәрия Мизхәт кызының күпьеллык намуслы хезмәте югары бәяләнә. Ул – I категорияле укытучы, “Мәгарифтәге казанышлары өчен” билгесе (2001), Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. РФ фән һәм мәгариф министрлыгы грамотасына (2008) лаек була. Ул 33 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый.

“Минем өчен бүләкнең иң зурысы – укучыларымның тормышта үз юлларын табуы, инде үзләренең чәчләренә чал керсә дә, хөрмәтләп, сагынып очрашулары, эти-әниләрнең рәхмәтле карашы. Мондый бәхетне бернинди дан-дәрәҗәләргә, мактаулы исемнәргә дә алыштырып булмый. Һәркемгә шушы шатлык насыйп булсын”, - дигән теләктә кала Сәрия Мизхәтовна.



# Юнысов Марсель Мирхәйдәр улы

Әлмәт физик культура техникумын тәмамлап, 1973 нче елда Күбәк урта мәктәбенә эшкә килә. Шушы мәктәптә 35 ел балаларга белем һәм тәрбия бирә.

Яшь белгеч дәресләрне югары методик хәзерлек белән үткәрә, материаль базаны туплау буенча зур тырышлык куя. Волейбол, баскетбол, көрәш, җиңел атлетика, чаңгы түгәрәкләре оештыра, класстан тыш чараларга барлык укучыларны тарта, сәләтле балалар белән индивидуаль эшли. Мәктәпнең җыелма командасы район, республика ярышларында зур уңышларга ирешә. Көрәш буенча команда 4 ел рәттән 1 нче урынны ала, кубок Күбәк мәктәбендә кала.

Чаңгы ярышларында команда призлы урыннардан төшми. Район чемпионнары күп була. 10 тапкыр команда 1 нче урынны ала. Республика ярышларында катнашкан укучылар була.

Фәиз Хуҗин призына үткән ярышларда команда 12 тапкыр беренче урынны ала. Волейбол, баскетбол командалары район чемпионнары була. Республика ярышларында катнашалар.Фәиз Хуҗин призына үткән многоборье ярышларында 4 ел рәттән команда җиңү яулый. 1 укучы республика ярышларында 3 нче урынны ала. Туризм буенча 5 ел рәттән команда 1 нче урынга лаек була.

Һәр ел рәттән хоккей мәйданчыгы булдырыла. Хоккей командасы күп еллар районда җиңү яулый.

Җиңел атлетика буенча озынлыкка сикерү, якын арага йөгерү, биеклеккә сикерү, граната ыргыту буенча район чемпионнары була. (Кубоклар мәктәптә саклана).

I категорияле укытучы, “Лучший работник физической культуры” (1986), “Отличник физической культуры” (2004), “Мәгарифтәге казанышлары өчен” (2004) билгесе белән бүләкләнә, “Иң яхшы район тренерлары” исемлегенә кертелә, күп санлы Мактау кәгазьләренә лаек була, “Хезмәт ветераны”, “Юбилей медале” (1970) иясе.

Хәзерге көндә Марсель Мирхәйдәр улы лаеклы ялда.

## Арсланов Мирхаҗиян Гыйният улы



1943 нче елның 10 декабрендә туган.Мирхаҗиян Гыйният улы 1967 нче елда Әлмәт физкультура техникумына укырга керә. Анда яхшы билгеләргә генә укый. Бик күп спорт ярышларында техникум данын яклый. 1969 нчы елда уку йортын тәмамлап, үзенең туган якларына кайта.

1969 – 1970 нче уку елында Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбенә физкультура һәм башлангыч хәрби әзерлек укытучысы булып эшкә урнаша.

Армия сафларында да үзен өлгер, тырыш икәнлеген күрсәтә. Нинди генә эшкә алынса да, сынатмый егет.

Егетләрне Ватаныбызны саклау өчен әзерләүдә дә Мирхаҗиян абыйның көче аз кермәде. Аның көче белән әзерләнгән командалар районыбызда призлы урыннар-да гына булды.

Ул үзенең бар көчен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый. 33 еллык хезмәт стажы шушы мәктәптә үтә.

Мирхаҗиян абыйның укучылары, хәзерге эти-әниләр, аның кырыс та таләпчән дә булуын һәм аның мондый тәрбия бирүе тормышта бик кирәклеге турында сагынып сөйлиләр.

2003 нче елдан Мирхаҗиян абый Арсланов лаеклы ялда. Үзенең төпле, акыллы киңәшләре белән ул хәзер дә безнең белән янәшә.

# Шәмсиахметова Рәзимә Мөхәммәдин кызы



Татарстан республикасы Сарман районы Сарайлы авылында 1948 елның 25 июнендә дөньяга килгән.

Әти-әнисе гади колхозчылар булган, бала чагы бик тырыш, тату, дини гаиләдә үтә, гаиләдә 6 бала үсәләр. “Кичләрен әти-әнием я газета укыйлар, я бер-берсенә “Коръән“ аятьләрен сөйлиләр иде, миңа дини белем балачактан ук сеңеп калган,” - дип уртаклашты Рәзимә апа.

Башлангыч белемне авыл мәктәбендә, урта белемне Минзәләбаш мәктәбендә ала. Сәүдә институтына укырга кереп, көндезләрен эшли. 1970 елны Вәрәшбаш авылы егете белән тормыш кора.1973 нче елда дәүләт имтиханнарын унышлы тәмамлап, ике югары белемле белгеч Мөслим районы Иске Карамалы авылына юллама белән эшкә кайталар. Әскәр абый участок больницасына баш врач булып урнаша, Рәзимә апага белгечлеге буенча авылда эш булмый. Рус телен камил белгәне өчен, аны мәктәпкә рус теле һәм әдәбияты дәресләрен укытырга билгелиләр. Тора-бара педагогик белем алу теләге белән, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә һәм аны кызыл дипломга тәмамлый. “Эшләү дәверемдә әллә нинди дан-дәрәҗәләргә ирешмәсәм дә, укучыларымның мине кочаклап рәхмәт әйтүләре, бәйрәмнәрдә һәм туган көннәремдә котлаулары – болар бит үзе бер дәрәҗә белән дә тиңләрлек түгел,”- дип уртаклаша Рәзимә Мөхәммәтдиновна.

Бүгенге көндә Рәзимә Мөхәммәтдиновна лаеклы ялда.



# Бикмурзина Динә Дамустан кызы

1956 нчы елның 25 нче февралендә, Башкортостан республикасы Нариман районы Нөкәрле авылында туган. Ул таләпчән, тәртипне нык тотучы укытучы гаиләсендә туып үсә. Әтисе Ногман тарих, әнисе география фәннәрен укытканнар.

Динә Дамустановна мәктәптә бик яхшы укый. Үз-үзенә бик таләпчән була, спорт белән шөгыльләнә, мәктәптә үткәргән бер чарадан да читтә калмый. 1973 нче елны урта мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң, ул җиңел сәнәгать көллиятенә укырга керә. Көллиятне тәмамлаганнан соң, 1974 нче - 1981 нче елларда Казан шәһәре валяльный комбинатка эшкә урнаша. Шул чорларда кичләрен тегү һөнәрен үзләштерә. Шулай ук комсомол оешмасы эшләрендә катнаша, Рагъде Халитов җитәкчелегендәге Казан хоры солисткасы була.

1977 нче елда Бикмурзин Шарипҗан абый белән гаилә коралар. Институтны тәмамлаганнан соң, юллама белән алар, яшь белгеч буларак, Мөслим районына кайталар. 1978 – 1982 нче елларда Динә Дамустановна Күбәк урта мәктәбендә тәрбияче вазыйфасын башкара. Яшь гаиләне яңа эш урынына күчергәнлектән, 1983 -1988 нче елларда Динә апа Мөслим авылында РПУ да тегүче булып эшли. 1991 нче елда язмыш җилләре Динә апаны кабат Күбәк мәктәбенә кайтара. Һәм шул көннән башлап 2009 нчы елга хәтле Күбәк мәктәбендә хезмәт укытучысы булып эшли.

Динә Дамустановна эшләү дәверендә үзен эзләнүчән, укыту методикасын яхшы белә торган, таләпчән педагог итеп таныткан укытучы. Балаларга төпле белем бирергә тырышу, эзләнү, яңалыкка, фәннилеккә омтылу эзсез калмый. 2002 нчы елдан алып 2009 нчы елга хәтле ул район методик берләшмәсенең җитәкчесе була, егерме елга якын сыйныф җитәкчесе вазыйфаларын башкара. Аның укучылары хезмәт фәне буенча олимпиадаларда һәр елны призлы урыннар яулый.

Динә апа 2020 нче елда каты авырудан вафат була.

# Бакыева Зинира Назар кызы



Бакыева Зинира Назар кызы 1961 нче елның 12 нче сентябрендә Мөслим районы Әлмәт авылында туа.Иске Әлмәт авылында башлангыч белем алгач, укуын Әмәкәй сигезьеллык мәктәбендә дәвам итә.Алар анда интернатта торып укыйлар.Урта белемне Актаныш районы Чуракай урта мәктәбендә ала. Кулына өлгергәнлек аттестаты алган Зинира Алабуга шәһәренә юл тота. Керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Алабуга дәүләт педагогия институтының физика бүлегенә укырга керә.

1984 нче елда кулына диплом тоткан яшь чибәр укытучы Түбән Табын мәктәбенә эшкә кайта.Аңа математика дәресләре бирәләр. Күп тә үтми , ул шушы авылда тормыш иптәшен -Рафисны очрата. 1985 нче елда гөрләтеп туйлар уздырып гаилә коралар. Ә 1986 нчы елда яшь гаилә Күбәк авылына күченеп килеп яши башлый. Ул вакытта укучылар бик күп була, параллель классларда укыталар.

35 ел математика фәнен укыту дәверендә Зинира Назаровна бик күп укучыларга ныклы белем бирә. Математиканы аеруча яратып укыган көчле укучыларын ул сагынып һәм горурланып искә ала. Алар - Юнысов Марат, Исламов Ринат, Валиева Гөлчәчәк, Гайсина Миләүшә, Исламова Резида, Асылгараева Земфира, Бакиева Элвира, Бикмурзина Айсылу, Карамова Айсылу. Аның укучылары югары уку йортларын тәмамлап, илебезнең төрле почмакларында яшиләр һәм эшлиләр.

Хезмәт еллары бик матур үтә, укытучылар бик матур итеп бәйрәмнәр дә уздыралар, укучылар белән бергә колхоз басуларында да эшлиләр.

Тормыш иптәше Рафис абый белән өч бала үстерәләр. Олы уллары Радик ветврач һөнәре ала, хәзерге вакытта әти-әнисенә төп таяныч булып алар янында яши. Икенче уллары Заһир гаиләсе белән Чаллы шәһәрендә яши. Кызлары Эльвира республика клиник хастәханәсендә шәфкать туташы булып эшли.

Бүгенге көндә Зинира Назаровна бакчасында матур гөлләр үстереп, балаларының һәм үзе укыткан укучыларының уңышларына сөенеп , тормыш иптәше Рафис абый белән тыныч кына гомер итәләр.

## Рахимова Дилә Хәй кызы



Туган ягы – җырларда җырланган ямьле Актаныш яклары.1964 нче елның 15 нче мартында Иске Богады авылында дөньяга килгән. Шушы авылда урнашкан Богады урта мәктәбендә урта белем алган, октябрят, пионер, комсомол сафларында тәрбияләнгән. Балачак елларында үк бөреләнгән хыялы Алабуга дәүләт педагогия институтының филология бүлегенә алып килә. 1986 нчы елда, уку йортын уңышлы тәмамлап, юллама буенча Күбәк урта мәктәбенә килә һәм хезмәт юлын рус теле һәм әдәбияты укытучысы, өлкән пионервожатый булып башлый. Берничә елдан директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп билгеләнә, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып бара. Заман һәр чорда мәгариф өлкәсенә яңа таләпләр куя. Ул да, хезмәттәшләре белән бергәләп, шуларны үтәргә, укучыларга сыйфатлы белем һәм тәрбия бирергә омтыла. “Тәрбия эшләре белән идарә итүче буларак, коллективта уңайлы тәрбияви мохит булдыру, тәрбия чараларын үтемле итеп оештыру, әхлаклы, әдәпле, хезмәт сөючән иҗади шәхесләр тәрбияләүне төп бурычларымдип санадым,” –ди Зилә Габделхәевна. Ә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда якташ әдипләр иҗатын өйрәнүгә, сүз сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләүгә аерым игътибар бирә.

Гомер аккан сулар кебек уза. Өч дистәгә якын гомерен яраткан һөнәренә багышлавы белән, ул үзен бик бәхетле дип саный. “Хезмәт юлымда маяк булып торган остазларым Вәлиев Зәйнәгытдин Вәҗи улына, Исхакова Сөгъдә Идрис кызына, Вәлиева Рәйфә Хатыйп кызына, Шәмсиахметова Рәзимә Мөхәмәтдин кызына, Юнысов Марсель Мирхәйдәр улына, Юнысова Сәрия Мизхәт кызына һәм башка бик күпләргә мин бик рәхмәтле,” - ди.

Укытучы булу – һөнәр генә түгел, барлык тормышы да. Бөтен яшәве, кызыксынулары, омтылышлары – барысы шушы бер юлга барып тоташа.

## Шәнгәрәева Зөлфирә Ягъсуп кызы



1965 нче елның 23 нче маенда Мөслим районы Баек авылында дөньяга килгән. 1972 нче елда беренче класска укырга кереп, 1982 нче елда урта мәктәпне тәмамлаган һәм шул ук елны АДПИның башлангыч класс укытучылары әзерли торган бүлегенә укырга кергән. 1986 нчы елда институтны тәмамлап, Мөслим районына юллама белән эшкә кайта. Баек мәктәбенә башлангыч класслар укытучысы итеп эшкә билгеләнә. Язмыш булгандыр инде, үз теләге белән Күбәк урта мәктәбенә эшкә килә. Лаеклы ялга туктаганчы, шушы мәктәптә укыта.

Күбәк урта мәктәбенә эшкә килгәч, тормыш иптәшен - Равил улы Зәлифне очрата һәм 1987 нче елны алар тормыш кора. Ике ул һәм бер кыз үстерәләр. Бүгенге көндә балаларның үз тормышлары. Илфар Казанда стандарт булмаган конструкцияләр буенча инженер булып эшли. Ә Илнур газпромда хезмәт куя. Кызлары Энҗе әтисе юлыннан китә, ул Минзәләдә лесхозда инженер булып эшли. Киленнәре дә, Зөлфирә Ягъсуповна кебек, укытучы булып эшлиләр.



## Хафизов Әхәт Әхтәм улы

1976 нчы елдан 2007 нче елга кадәр Күбәк урта мәктәбендә хуҗалык эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. Егетләргә трактор һәм башка авыл хуҗалыгы техникасы белән идарә итү серләрен дә өйрәтә. Ул чорларда район мәктәпләренә үрнәк булган хезмәт кабинетында да эшчәнлеге зур булды. Әхәт Әхтәмович кабинет җитәкчеләренә стендлар язуда бик күп ярдәм күрсәтә. Стена газеталарында матур итеп ясаган рәсемнәрен өлкән буын кешеләре хәзер дә искә ала.

Бүгенге көндә лаеклы ялда.

# Хәйдәрова Ләйсән Имам кызы



1952 нче елның 5 нче мартында Калинин районы Иске Үрәзмәт авылында Имам һәм Флүрә Гайниевлар гаиләсендә беренче бала булып дөньяга аваз сала. Башлангыч мәктәпне,урта белемне туган авылында ала. Оештыру сәләте мәктәп елларында ук ачыла, отряд вожатые, дружина советы председателе вазыйфаларын зур осталык белән башкара. Мәктәп комсоргы була.

1969 нчы елда Күбәк урта мәктәбенә башлангыч класс укытучысы булып эшкә килә.

1972 нче елда хезмәт юлын Үрәзмәт урта мәктәбендә өлкән пионервожатый булып башлый.

Нәтиҗәле хезмәте өчен 2 ел эчендә ВЛКСМ Үзәк Комитетының “Лучшему пионерскому вожатому” һәм “50 лет Всесоюзной пионерской организации имени В.И.Ленина” дип исемләнгән значокларга һәм грамотага лаек була.

2003 елның 20 нче октябрендә, ЦК ВЛКСМ бүләкләре булгач, ветеран труда бирелә.

1974 нче елда Алабуга культура-агарту көллиятенең китапханә бүлеген тәмамлый.

1976 нчы елда кабат Күбәк урта мәктәбенә әйләнеп кайта. Озайтылган көн группасы, интернат тәрбиячесе булып эшли.1984 нче елдан хезмәт юлын китапханәче һөнәренә багышлый.

Ләйсән Имам кызы тыйнак,гади, гадел һәм шул ук вакытта таләпчән дә. Ул 1969 нчы елдан 2010 нчы елга кадәр башкарган хезмәт юлында үзен энергияле, оптимист,тапкыр сүзле, бик кешелекле, ярдәмчел кеше буларак күрсәтте. Укучыларда матур әдәбият әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү, китапханә фондын баету, класс җитәкчеләренә,укытучыларга методик ярдәм күрсәтү кебек эшләрне зур осталык, дәрт белән башкарды.

## Зарипова Фәния Нияз кызы




1958 нче елның 17 нче июнендә Мөслим районы Түреш авылында дөньяга килгән. 1965 нче елда Түреш башлангыч мәктәбенә укырга кергән. 1975 нче елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый. 1975-1980 нче елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетында белем алган.

1980-1982 нче елларда Түбән Табын урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыткан. 1982-1984 нче елларда Түреш башлангыч мәктәбендә эшләгән, тормыш иптәшен Әлмәт районына эшкә билгеләү сәбәпле, 1985-1993 нче елларда Әлмәт районында балалар бакчасы мөдире булып эшләгән.

1993 нче елда гаиләсе белән Яңа Карамалы авылына күченеп кайтканнар. Пенсиягә чыкканчы Яңа Карамалы башлангыч мәктәбендә укучыларга белем биргән. Монда Халиуллина Лилия Мирзанур кызы белән бергә эшләгән. Мәктәбебез һәрвакыт яхшы яктан гына телгә алынды, - дип искә ала Фәния Ниязовна. Эшләү дәверендә район мәгариф бүлегенең Рәхмәт хаты һәм грамоталар белән бүләкләнгән. Эшен  ата-аналар белән тыгыз элемтәдә алып бара. Мәктәптә балалар белән театр түгәрәкләре оештырып, әти-әниләр, авыл халкы алдында чыгышлар ясаганнар, Күбәк урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укучылары белән очрашып, аларга да әзерләгән спектаклебезне күрсәткән чаклары күп булган.

Һәр елны табигатькә экскурсияләргә чыктык,  Мөслимнең “Туган як” муззена, “Авыл утлары” газетасы редакциясенә экскурсияләргә бардык, картлар йортында концерт куйдык, әти-әниләр белән бергәләп, анда тәрбияләнүче әби-бабайларгабүләкләр, күчтәнәчләр алып бардык, - ди Фәния Ниязовна.

Укучылары  районда үткәрелгән олимпиадаларда катнашып, төрле дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләнгәннәр.  Алар, Күбәк урта мәктәбенә киткәч тә, укуларын төрле уку йортларында дәвам иттеләр. Һәркайсы тормышта үз юлын тапты.

## Сайранова Гөлфия Кәшбетдин кызы



1958 нче елның 4 июлендә Мөслим районы Дусай авылында туган.Әти-әнисенең канаты астында 6 бала үсәләр. Буй житкәч, авылны бик яраткангадыр инде, ике дә уйлап тормыйча фермага сыер саварга керә. Иң алдынгы сыер савучы исемен яулап, хәттә Германия белән Чехославакиягә путёвкага да лаек була Гөлфия апа. 1982 нче елда язмышын Иске Карамалы авылы егете белән бәйли, һәм Күбәк урта мәктәбенә пешекче булып эшкә килә. Балаларның, апа шундый тәмле итеп пешерәсез диюләре, үзе бер бәхет, - ди Гөлфия апа.

1982 нче елдан алып 2013 нче елга кадәр эшен жиренә житкереп шушы мәктәптә хезмәт куя. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

## Хафизова Фәйрүзә Миргалим кызы



1961 нче елны Мөслим районы Бәкәбез авылында туган. 1978 нче елда Күбәк мәктәбен тәмамлый. Бәкәбез авыл клубында худ рук булып эшли. 1980 нче елдан 1983 нче елга кадәр Күбәк балалар бакчасында хезмәт куя. 1983 нче елдан 2016 нчы елга кадәр Күбәк урта мәктәбендә техник хезмәткәр булып эшли. Бүгенге көндә лаеклы ялда.

## Ризванова Альфира Амиржан кызы



1957 нче елның 21 нче июлендә Мөслим районы Октябрь авылында туган. Башлангыч сыйныфларны сигезенче сыйныфка кадәр үз авылында, аннары Күбәк урта мәктәбендә дәвам итә. Укуны тәмамлагач, 1974 нче елда авыл китапханәсендә эшли. Соңрак Түбән Кама шәһәренә китеп урнаша, тормышка чыга. 1978 нче елда янә туган якларына кайтып урнашалар. 15 ел балалар бакчасында эшли. 1997 нче елдан алып 2012 нче елга кадәр Күбәк урта мәктәбе ашханәсендә хезмәт куя. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.